Раслыйм»
Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
«Чистай шәһәре» муниципаль
берәмлегенең җир биләмәләреннән
файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре
буенча комиссия рәисе

______________________И.Ф. Рәхимов

№ 10
2021 елның 11 августы

«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында һәм шартлы рәвештә рөхсәт ителгән җир кишәрлегеннән файдалану төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча

**БӘЯЛӘМӘ**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгының «Ачык тыңлауларны билгеләү турында» 2021 елның 1 июлендәге 11 номерлы, «Җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында» 2021 елның 13 июлендәге 12 номерлы карарлары белән билгеләнгән ачык тыңлаулар 2021 елның 11 августында 10 сәгать 00 минутта Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының зур залында түбәндәге адрес буенча узды: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129-нчы йорт.

«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча һәм 2021 елның 11 августындагы 10 номерлы җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар үткәрү беркетмәсе

**Ачык тыңлаулар предметы:**

1. Гр. И.А. Шәрифуллинның мөрәҗәгате буенча «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» проектын карау, Ж-1 «Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы» территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм Чистай шәһәре, Маркин ур., 16А з/у территориясен, шул исәптән кадастр номеры 16:54:030104:468 булган, 466 кв. м мәйданлы җир кишәрлеген, Д-1 «Эшлекле, иҗтимагый һәм коммерция билгеләнешендәге зона» зонасына кертү өлешендә.

2. Чистай шәһәре мөхтәсибәтенең мөрәҗәгате буенча «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» проектын карау, Р-1 «Рекреацион-ландшафт территорияләре зонасы» территориаль зонасы чикләрен үзгәртү һәм Чистай шәһәре, Энгельс ур., 154 з/у территориясен, шул исәптән кадастр номеры 16:54:020103:570 булган, 7000 кв. м мәйданлы җир кишәрлеген, Д-5 «Дини билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы» зонасына кертү өлешендә.

3. Богданова Татьяна Юрьевнаның, кадастр номеры 16:54:050202:425 булган, 152 кв.м. мәйданлы, Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Бутлеров ур., 45Б - «Кибетләр» Ж-1 «Индивидуаль торак йортлар салу

зонасы» зонасында урнашкан җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы мөрәҗәгате буенча.

**Карар иттеләр:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлауларны узган дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәреш кертү турындагы проектларны хупларга һәм аны раслау өчен «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Советына җибәрергә.

3. Богданова Татьяна Юрьевнага, кадастр номеры 16:54:050202:425 булган, 152 кв.м. мәйданлы, Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Бутлеров ур., 45Б - «Кибетләр» Ж-1 «Индивидуаль торак йортлар салу зонасы» зонасында урнашкан җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирергә.

4. Әлеге бәяләмәне Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Комиссия сәркатибе: ____________________Хөснетдинов А.Н.